| | |
|---|---|
| **ГЛАВА<br>КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2022 ел Колаңгы станциясе № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Колаңгы авыл җирлеге Бәли
торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2022 елның 24 ноябрендә 10 сәг 00 минутка Бәли авылы , Кызыл урамы, 63А йорт адресы буенча , үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 24 ноябрендә 14 сәг 00 минутка Бәли авылы , Кызыл урамы, 18 йорт адресы буенча , үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын икенче этабын билгеләргә

3.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- җирлектэге торак пунктлардагы санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып балалар мәйданчыгын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;

*б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм ремонтлау, материаллар алу;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- жирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Интернет - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең http://kulangin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колангы авыл жирлеге башлыгы** **Ф.Т.Нигматзянов**